ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законының $10^1$ статьясына үзгәреш кертү хакында» 445-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты А.В. Тыгин тарафыннан кертелгән «Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законының $10^1$ статьясына үзгәреш кертү хакында» 445-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2023 елның 13 июле
№ 2060-VI ДС

Проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутаты
А.В. Тыгин
тарафыннан кертелә

**«Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законының $10^1$ статьясына үзгәреш кертү хакында»**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү турында» 2011 елның 10 октябрендәге 72-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының $10^1$ статьясындагы 8 өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2011, № 10 (I өлеш); 2012, № 11 (I өлеш); 2015, № 4; 2016, № 7 – 8; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 27 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 29 (I өлеш), № 54 (I өлеш); 2019, № 28 (I өлеш); 2020, № 37 (I өлеш); 2021, № 29 (I өлеш), № 93 (I өлеш); Татарстан Республикасының Рәсми хокукый мәгълүмат порталы (PRAVO.TATARSTAN.RU), 2023 елның 21 июне), «дәүләт хакимиятенең вәкаләтле органы яисә җирле үзидарә органы, Россия Федерациясе яисә Татарстан Республикасы тарафыннан төзелгән һәм Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә территорияне комплекслы үстерү турындагы карарны гамәлгә ашыруны тәэмин итә торган юридик зат» сүзләрен «торак төзелеше территориясен комплекслы үстерү турындагы карарның гамәлгә ашырылуын тәэмин итүче Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында күрсәтелгән затлар» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законының $10^1$ статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына аңлатма**

«Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законының $10^1$ статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты «Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү турында» 2011 елның 10 октябрендәге 72-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (алга таба – 72-ТРЗ номерлы Закон) «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 24 июнендәге 276-ФЗ номерлы Федераль законга туры китерү максатларында эшләнде.

Әлеге Федераль закон белән Россия Федерациясе Торак һәм Шәһәр төзелеше кодексларының торак төзелеше территориясен комплекслы үстерү турындагы нормаларының төрлечә укылышын бетерү максатларында Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының $32^1$ статьясына үзгәрешләр, шул исәптән алар белән торак төзелеше территориясен комплекслы үстерү хакында шартнамә төзелергә мөмкин булган затларның исемлеген төгәлләштерүгә юнәлдерелгәннәре дә, кертелде.

Закон проекты белән 72-ТРЗ номерлы Законның $10^1$ статьясындагы 8 өлешенә шундый ук үзгәрешне кертү тәкъдим ителә, ул комплекслы үстерелергә тиешле торак төзелеше территориясе чикләрендәге торак урыннар милекчеләренә һәм аларны яллаучыларга алмашка бирелә торган шундый ук торак урынны (торак бәясенә тиң түләүне яисә, торак урынның бәясен кертеп, торак урынны) торак урын милекчесе һәм торак төзелеше территориясен комплекслы үстерү турындагы карарның гамәлгә ашырылуын тәэмин итүче Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында күрсәтелгән затлар йә, торак төзелеше территориясен комплекслы үстерү хакындагы шартнамәдә каралган очракта, территорияне комплекслы үстерү турындагы мондый шартнамә төзегән зат арасында төзелә торган шартнамә нигезендә бирүне күздә тота.

**«Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законының $10^1$ статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалтуы танылырга, туктатып торылырга, үзгәртелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары исемлеге**

«Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законының $10^1$ статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы законнарының һәм башка норматив хокукый актларының үз көчләрен югалтуын тану, аларны туктатып тору, үзгәртү яисә башкаларын кабул итү таләп ителми.

**«Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законының $10^1$ статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына финанс-икътисадый нигезләү**

«Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законының $10^1$ статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән каплана торган өстәмә чыгымнарны таләп итми.